**Республика Татарстан САКЛОВ-БАШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ул. Ленина, д. 93 а,
с. Саклов-Баш, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Ленин урамы, 93 а йорт,
Саклаубаш авылы, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

ИНН/КПП 1636005510/164701001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.05.2021 г. № 17

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Саклаубаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 27 февралендәге 27-ФЗ номерлы Федераль закон (2020 елның 1 апреленә үзгәрешләр белән), «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 24 апрелендәге 148-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 9 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 241-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 46 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 9 ноябрендәге 363-ФЗ номерлы номерлы Федераль закон, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 29 декабрендәге 464-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2017 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Саклаубаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 78-80 статьяларына,

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 9 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Саклаубаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Саклаубаш авыл җирлеге
Советы Рәисе Л. М. Габидуллина

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге
советының 2021 елның 6 маендагы
17 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Саклаубаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 7.1 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 һәм 18 пунктлар өстәргә:
17) полиция участогы уполномоченный вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү;
18) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.»;
2. 16 статьяның 9 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:
7) инициативалы проектн буенча фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.»;
3. 16 статьяны түбәндәге эчтәлекле 10_1 өлеше белән тулыландырырга:
«10_1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары инициативалы проектны проект инициаторлары буларак тәкъдим итә алалар.»;
4. 18 статьяның 1 өлешендә «Җирлекнең җирле үзидарә вазыйфаи затларын билгеләү» сүзләреннән соң «инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу» сүзләрен өстәргә;
5. 18 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән әлеге территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициативалы проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе Җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;
6. 20 статьяның 2 өлешенә түбәндәге сүзләр өстәргә: «Гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча сораштыруда инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән җирлек яисә аның өлешендәге уналты яшькә җиткән яшәүчеләр катнашырга хокуклы»;

7. 20 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:
«3)инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән уналты яшькә җиткән җирлек яисә аның бер өлеше халкы - әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

8. 20 статьяның 5 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:
«6) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе;
9. 20 статьяның 5 өлешендә беренче абзацында «Җирлек Советы». Җирлек Советы карарында» сүзләрен «Җирлек Советы» сүзләренә алмаштырырга. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча файдаланырга мөмкин: sarmanovo.tatarstan.ru. Гражданнар арасында сораштыру билгеләү турында җирлек

Советының норматив хокукый актында түбәндәгеләр билгеләнә:».

10. 20 статьяның 7 өлешендәге 1 пунктына «яисә Җирлек халкы» сүзләрен өстәргә;
11. 43 статьяның 1 өлешендәге 2 һәм 3 абзацларын төшереп калдырырга;
12. 43 статьяның 2 өлешен түбәндәге эчтәлекле 15 һәм 16 пунктлар белән тулыландырырга:
«15) алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру;
16) полиция участогы уполномоченный вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү;»

13. 44 статьяның 2 өлешендәге 3 абзацында «әлеге Федераль законның 35 статьясындагы 17 пунктында каралган Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр тәкъдимнәре» сүзләрен төшереп калдырырга;
14. 44 статьяның 2 өлешендәге 10 абзацында «шулай ук «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 35 статьясындагы 17 пунктында каралган Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;
15. 49 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Җирлек Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими булмаган рәвештә гамәлгә ашыру өчен, айга дүрт эш көне чорында эш урынын (вазыйфасын) саклау гарантияләнә».

16. 58 статьяның 3 өлешен түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:
3) Гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары.».

17. 70 статьяның 3 өлеше үз көчен югалткан дип танырга;
18. 80 статьяның 2 өлешендә «аны» сүзен төшереп калдырырга, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Җирлек Советы карары турында белдерү кәгазе» сүзләрен өстәргә.